МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ГОСУДАРСТВЕННОЕ АВТОНОМНОЕ ПРОФЕССИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ

«АКТАНЫШСКИЙ ТЕХНОЛОГИЧЕСКИЙ ТЕХНИКУМ»

# ОУД.12. «Родная литература»

## Комплект контрольно-оценочных средств

## по специальности 09.02.07. Информационные системы и программирование

Актаныш, 2022

# Эчтәлек

бит

1. **Студент нәрсә белергә һәм нәрсә эшли белергә тиеш** **5**

2. **Контроль билге кую - тикшерү–бәяләү төрләре һәм алымнары** **6 - 13**

3. **Кулланылган әдәбият** **14**

4. **Студентларнын белемнәрен бәяләү** **15 - 16**

Бу тикшерү – бәяләү алымнары **Мәгълүмати системалар һәм программалаштыру белгечлеге хәзерле торган группа студентлары** өчен төзелде (022 эр)

Мәҗбүри уку дәресе - 82 сәгать

**Йомгаклау аттестациясе** – дифзачёт

***Татар әдәбияты фәнен үзләштергәннән соң студент* белергә тиеш:**

Язучыларның, шагыйрьләрнең, драматургларның тормыш юлларын, иҗатын;әдәбият тарихын, татар әдәбиятының төрле чорында иҗат ителгән әсәрләрнең эчтәлеген; шигырьләрне сәнгатьле укый, яттан сөйли; татар әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны, төп әдәби – теоретик төшенчәләр; халык авыз иҗаты һәм әдәбият; татар әдәбияты тарихын чорларга бүлә белү; әдәби әсәрләрнең төзелешен (тема, идея, сюжет, композиция, образлар системасы һ.б.) анализлый белү; матур әдәбияттагы мәңгелек темалар, әдәбиятның башка сәнгать төрләре белән бәйләнеше.

**Эшләргә тиеш:** Текстка дөрес бәя биреп, үз сүзләре белән нәтиҗә ясау; әсәргә телдән һәм язмача план төзү; әдәби әсәрләрнең жанрын аера белергә; образларга характеристика бирергә, фикерләрен ачык, төгәл итеп әйтеп бирергә. Укылган әсәрнең нинди чорга кагылышлылыгын бүгенге көн белән чагыштырып карый белү. Әсәргә тулы анализ ясый белергә. Текстның исеме, андагы таныш исемнәр ярдәмендә укучыларның эчтәлекне аңлаулары; укылган текст буенча әңгәмәдә катнаша алу; өйрәнелгән язучылар турында сөйли белү; укылган текстның эчтәлеген сөйли һәм нәтиҗә ясый белү, аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу.

## Татар әдәбияты фәне буенча дифзачёт (сочинение) алу өчен материал

1. Сигез гасыр элек җырларыңны
Яраткан да халык ятлаган.
Шуннан бирле аны онытмаган,
Күңелендә көйләп саклаган.
*(Кол Гали иҗаты буенча.)*

2. Каюм Насыйри һәм татар халык авыз иҗаты.

3. Габдулла Тукай – кеше һәм шагыйрь.

4. “Дөньяда шундый итеп яшәргә кирәк: үлгәннән соң да үлмәслек булсын, яшәүнең бөтен максаты шунда түгелмени?!”
(Муса Җәлил)

5. С. Хәким — халык рухын бөеклеккә күтәрүче шагыйрь.

6. Тик шунысы хак: фәкать туган телдә
Иман иңә кеше җанына.
*(Р. Фәйзуллин)*

7. Мин сезгә үземнең яраткан әсәрем турында язарга телим...

## Татар әдәбиятыннан контроль тест биремнәре

**1. XX йөз башы татар әдәбиятының хронологик чикләре.**
А - 1901-1917
Ә - 1905-1918
Б - 1895-1917
В - 1908-1917
**2. XX йөз башында нәшер ителгән иң озын гомерле газета**.
А - Фикер"
Ә - "Вакыт"
Б - "Йолдыз"
В - "Тормыш"
**3. Инкыйлаби-демократик юнәлешле газета.**
А - "Вакыт"
Ә - «Казан мөхбире»
Б – «Таң йолдызы»
В - "Нур"
**4. Рәсми рөхсәт белән татар телендә уйналган "Өч хатын белән тормыш" драмасының вакыты**.
А - 1906, 22 декабрь
Ә - 1904, 4 апрель
Б - 1906, 21 апрель
В - 1906, 5 май
**5. 1906 елның 5 маенда Казанда рәсми төстә уйналган спектакль.**
А - "Өч хатын белән тормыш"
Ә - "Бичара кыз"
Б - "Кызганыч бала"
В - "Ике гашыйк"
**6. Яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салучы әдип.**

А - Ф.Әмирхан
Ә - Г.Камал
Б - Ш.Камал
В - Г.Исхакый

**7. Реалистик юнәлеш билгесе**.
А - дошмани тирәлектә яшәүче гыйсъянчы геройның эчке дөньясын сурәтләү
Ә - хис культы
Б - серлелеккә, билгесезлеккә омтылу
В - кешене тирәлек җимеше итеп сурәтләү

**8. Г.Исхакыйның "Сөннәтче бабай" хикәсендә иң зур әдәби-эстетик мәгънә салынган деталь төре**.
А - пейзаж
Ә - психологизм
Б - әйберләр, предметлар
В - портрет

**9. Г.Исхакый иҗатында төп тема.**
А - милләт язмышы
Ә- тарихи тема
Б - зыялылар темасы
В - хатын-кыз темасы

**10. Ф.Әмирханның "Хәят" повестендагы төп каршылык.**
А - ата һәм бала
Ә - искелек һәм яңалык
Б - социаль каршылык
В - эчке каршылык

**11. Хатын-кыз портретларында Ф.Әмирхан аеруча зур игътибар иткән деталь.**
А - буй-сын
Ә - иреннәр
Б - күзләр
В - чәчләр

**12. Төркиядә белем алган әдип.**
А - М.Фәйзи
Ә - Г.Ибраһимов
Б - Дәрдемәнд
В - С.Сүнчәләй

**13. Дәрдемәнд лирикасына хас хис.**
А - борчылу
Ә - шатлык
Б - шөбһәләнү
В - сагыш

**14. Г.Ибраһимов мирасында илаһи мәхәббәт тасвирланмаган әсәр.**
А - "Сөю-сәгадәт"
Ә- "Табигать балалары"
Б- "Яшь йөрәкләр"
В - "Уты сүнгән җәһәннәм"

**15. Г.Ибраһимовның "Табигать балалары" хикәясендә күтәрелгән мәсьәлә.**
А - яшәү мәгънәсе
Ә - табигать һәм кеше мөнәсәбәте
Б - зыялыларның рухи эзләнүләре
В - кеше бәхете

**16. "Уты сүнгән җәһәннәм" (Г.Ибраһимов), "Тормышмы бу?" (Г.Исхакый), "Картайдым" (Ф.Әмирхан) әсәрләрен берләштерүче сыйфат.**

А - миллилек
Ә - халыкчанлык
Б - яшәү мәгънәсен эзләү
В - романтик сурәтлелек
**17. Традицион шигырь калыбын җимерүче шагыйрь.**
А - Г.Тукай
Ә - С.Рәмиев
Б - Ш.Бабич
В - Н.Думави
**18. Г.Камалның "Беренче театр" комедиясендәге төп каршылык.**
А - Биби - Фатих
Ә - Факиһә - Хәбибрахман
Б - Хәмзә бай - балалары, якыннары
В - Вәли - Гафифә
**19. "Галиябану" әсәренең (М.Фәйзи) милли әдәбиятка алып килгән яңалыгы.**
А - композициясе
Ә - жанры
Б - темасы
В - образлар системасы
**20. "Галиябану" музыкаль драмасының (М.Фәйзи) үзәк каршылыгын аерып әйтегез.**
А - Галиябану-Бәдри
Ә - Галиябану-Исмәгыйль
Б - Исмәгыйль - тирәлек (егетләр)
В - Исмәгыйль-Хәлил
**Тестны бәяләү.**

| | |
|---|---|
| Биремнәр | 1-20 |
| Баллар | Һәр дөрес җавапка 1-шәр балл |

Максималь балл - 20
18-20 балл – “5”
14-17 балл- “4”
10-13 балл- “3”
10 баллдан кимрәк- “2”

## Татар әдәбиятыннан контроль тест биремнәре

1 курслар өчен

1. Чит илләрдә яшәп иҗат иткән нинди язучыларыбызны беләсез?
**Г. Исхакый, Х Хәмиулла, Х. Габдүш**
2. Г. Исхакыйның нинди әсәрләрен беләсез?
3. Татар язучыларының беренче съезды кайчан һәм кайда үткәрелә?
1934, 25-29 июнь
4. Г. Бәшировның “Сиваш” повестенда кайсы чор вакыйгалары сурәтләнә? (гражданнар)
5. 30 нчы еллар шагыйрьләрен языгыз:
М.Җәлил, Х.Туфан, Ә.Фәйзи, С.Баттал, Ш.Маннур, Ф.Кәрим, С.Хәким, Н.Баян.
6. 30 нчы еллар поэзиясенең төп җитешсезлеге?
(җанлы кешене, рухи дөньясын лозунглар белән алыштыру; ислам динен, зыялы кешеләрне явызлар дәрәҗәсенә төшерү)
7. Н.Исәнбәтнең халык авыз иҗатын туплаган җыентыгы?
(3 томлык “Татар халык мәкальләре)
8. Н.Исәнбәтнең “Идегәй” әсәренең жанры.
(трагедия)

9. Сугыш чорында иҗат ителгән проза әсәрләре эчтәлек буенча нинди 3 төркемгә бүленә?
1-җиңүгә ышаныч
2-фашистларның ерткычлыгы
3-кешеләрнең күңел дөньясы
10. Роман төрләре:
(детектив, тарихи-сәяси, тарихи, тарихи-биографик, документаль публицистик)
11. Ф. Кәримнең нинди поэмаларын беләсез?
( "Гөлсем", "Тимер һәм тимерче", "Үлем уены", "Партизан хатыны", "Кыңгыраулы яшел гармун")
12. Нәфисә кайсы әсәрнең төп герое?
13. Х.Туфан ничә ел тоткынлыкта булган?
14. М. Җәлилнең сугыштагы батырлыкларын сурәтләгән шигырьләр җыентыгы?
15. Түбәндәге өзекләр кайсы авторның нинди әсәреннән?
"Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә..."
"Поезд китте, ялгыз кабер торып калды..."

**Эшне бәяләү.**

| Биремнәр | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Баллар | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |

Максималь балл – 15
14-15 балл- «5»
11-13 балл- «4»
7-10 балл- «3»
7 баллдан кимрәк -"2"

## Студентларның татар әдәбиятыннан белемнәрен тикшерү өчен тестлар

**1. Язу һәм язма әдәбият туу һәм үсү өчен нинди шартлар кирәк?**
а) дәүләтчелек, утрак тормыш, шәһәрләр булу, башка илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә тору;
ә) дәүләтчелек, күчмә тормыш, күчеп йөрү өчен җәйләүләр, башка илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә тору;
б) аерым – аерым кабиләләр булып яшәү, башка илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә тору.
**2. Туран (һун) язуы белән язылган нинди истәлекләр сакланган?**
а) каберташлар;
ә) савыт – саба, алкалар;
б) язма әдәбият.
**3. Рун алфавиты кайсы чорларда гамәлдә йөри?**
а) V – X гасырда;
ә) XII йөзләрдә;
б) VII, VII – XIV йөзләрдә.
**4. Рун язма истәлекләренә нәрсәләр керә?**
а) язма әдәбият;
ә) савыт – саба, алкалар;
б) эпитафик, ягъни каберташ язмалары;
**5. "Диване лөгатет төрек" ("Төрки телләр сүзлеге") җыентыгының авторы кем?**
а) Йосыф Баласагунлы;
ә) Мәхмүт Кашгарый;
б) Әхмәт Йүгнәки;
**6. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" дастаны кайсы чорга карый?**
а) Алтын Урда чоры;

ә) Иң борынгы язма әдәби мирас;
б) Болгар чоры;
**7. “Кыйссаи Йосыф”ның төп өлеше ничә фасылдан тора?**
а) 15;
ә) 8;
б) 18;
**8. Йосыфтагы хәлиткеч сыйфатлар?**
а) укымышлылык;
ә) сабырлык, тугрылык;
б) шәфкатьлелек;
**9. Кол Галинең фикеренчә бәхетле тормышның нигезе –**
а) бердәмлектә, татулыкта, кешелекле мөнәсәбәтләрдә;
ә) Йосыф кебек һәрьяктан камил затларда;
б) матурлыкта, көчтә, алдан күрүчәнлектә;
**10. “Хөсрәү вә Ширин”ның авторы?**
а) Хәрәзми;
ә) Котб;
б) Сәйф Сараи;
**11. Рәдиф нәрсә ул?**
а) шигырь төзелеше;
ә) Сәйф Сараи әсәренең исеме;
б) газәлдә кабатланып килүче аерым сүз яки сүзләр төркеме;
**12. Сәйф Сараи кайда туган?**
а) Казан шәһәрендә;
ә) Камышлы шәһәрендә;
б) Сарай шәһәрендә;
**13. Сәйф Сараиның әсәрләре?**
а) “Идегәй”; “Кодатгу белек”;
ә) “Гөлстан бит-төрки”, “Сөһәйл вә Гөлдерсен”;
б) “Хөсрәү вә Ширин”, “Күңел”;
**14. Газәл жанрына хас сыйфатлар?**
а) тартмалы композиция;
ә) башта 3 юлы үзара рифмалашкан, дүртенче юлы рифмасыз дүртьюллыклар, һәр строфа имди сүзенә төгәлләнә;
б) икеьюллык строфалардан – бәетләрдән төзелә, рифмалардан соң рәдиф кабатланып килә, уртача күләме 5 - 12 строфадан тора, ахырында автор үзенең исемен яки кушаматын куллана.
**15.** ***“Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,***
***Җир әйләнгән төсле кояш тирәли.”*** Бу өзекләр кайсы әсәрдән алынган?
а) “Хөсрәү вә Ширин”,
ә) “Сөһәйл вә Гөлдерсен”;
б) “Идегәй”;
**16. “Идегәй”нең жанры?**
а) поэма;
ә) дастан;
б) экият;
**17. “И Идел йорт, Идел – йорт**
**Идел эче имин йорт,**
**Атам кияү булган йорт,**
**Иелеп хөрмәт кылган йорт;**
**Анам килен булган йорт,**
**Иелеп сәлам биргән йорт; ...”** Бу юллар кайсы әсәрдән алынган?
а) “Кодатгу белек”;
ә) “Сөһәйл вә Гөлдерсен”;

б) “Идегәй”;

**18. Идегәйнең чын исеме?**

а) Идегәй;
ә) Котлыкыя;
б)Туктамыш;
в) Кобыгыл;

**19. Дастанга хас сыйфатлар?**

а) икеьюллык строфалардан – бәетләрдән төзелә, рифмалардан соң рәдиф кабатланып килә, уртача күләме 5 - 12 строфадан тора, ахырында автор үзенең исемен яки кушаматын куллана.
ә) башта 3 юлы үзара рифмалашкан, дүртенче юлы рифмасыз дүртьюллыклар, һәр строфа имди сүзенә төгәлләнә;
б) лиро-эпик характердагы әдәби әсәр. Анда вакыйга-хәлләр уй-кичерешләр белән үрелеп бара. Кагыйдә буларак әкияти сюжетлар, легенда-риваятьләр эшкәртелә, хыялый һәм чынбарлык күренешләре үзара үрелеп бара.

**Ачкыч:**

1 - а; 2 - ә; 3 - а; 4 - б; 5 - ә; 6 – а; 7 – б; 8 – ә; 9 – а; 10 - ә; 11 - б; 12 - ә;
13 – ә; 14 – б; 15 – ә; 16 - ә; 17 – б; 18 – в; 19 – б.

## Татар әдәбиятыннан контроль эш биремнәре

**1 курслар өчен**

**I. ТЕСТ:**

**1. Татар әдәбияты тарихы ничә чорга бүлеп өйрәнелә?** (1 балл)

а) 2
ә) 3
б) 4
в) 5

**2. Болгар чорына караган әсәрне билгеләгез:** (1 балл)

а) “Хөсрәү вә Ширин”
ә) “Кыйссаи Йосыф”
б) “Сөһәйл вә Гөлдерсен”
в) “Идегәй”

**3. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәре татар әдәбиятының кайсы чорына карый?**(1балл)

а) Болгар чоры
ә) Алтын Урда чоры
б) Казан ханлыгы чоры
в) иң борынгы әдәбият

**4. Әсәрләрне һәм авторларын туры китереп языгыз:** (4 балл)

а) “Нуры Содур”
ә) “Котадгу белек”
б) “Кыйссаи Йосыф”
в) Хикмәтләр
а) Мәүла Колый
ә) Кол Гали
б) Мөхәммәдъяр
в) Йосыф Баласагунлы

**5. Мәүла Колый нинди жанрда иҗат иткән?** (1 балл)

Хикмәт
б (Шигырь)
ә) Поэма
в (Дүртьюллыклар)

**6. “Тапшырылмаган хатлар” әсәренең авторы кем**? (1 балл)

а) Гадел Кутуй
ә) Кәрим Тинчурин
б) Муса Җәлил
в) Әмирхан Еники

**7.** *“Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,*
*“Ул егылган арып”, - дисәләр,*
*Син ышанма, бәгьрем! Мондый сүзне*
*Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр”,* **– дигән шигырь юлларының авторы кем?** (1 балл)

а) Фәнис Яруллин
ә) Муса Җәлил
б) Фатих Кәрим
в) Хәсән Туфан

**8. “Тапшырылмаган хатлар” әсәренең авторы кем**? (1 балл)

а) Гадел Кутуй
ә) Кәрим Тинчурин
б) Муса Җәлил
в) Әмирхан Еники

**9.** *“Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,*
*“Ул егылган арып”, - дисәләр,*
*Син ышанма, бәгьрем! Мондый сүзне*
*Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр”,* **– дигән шигырь юлларының авторы кем?** (1 балл)

а) Фәнис Яруллин
ә) Муса Җәлил
б) Фатих Кәрим
в) Хәсән Туфан

**10.** *“Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә*
*Һәм үләргә кыю ир булып.*
*Гомрем минем моңлы бер җыр иде,*
*Үлемем дә яңрар җыр булып”,* **– дигән юллар Муса Җәлилнең нинди шигыреннән?** (1 балл)

а) “Чәчәкләр”
ә) “Ышанма”
б) “Кошчык”
в) “Җырларым”

**11. “Разведчик язмалары” әсәренең авторы кем**? (1 балл)

а) Фатих Кәрим
ә) Сибгат Хәким
б) Муса Җәлил
в) Һади Такташ

**12.** *“Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә бөгәрләнеп ятты. Ятып күзләрен йомуга, ул, салкын бер чоңгылга баткандай, башта туңып китте. Күпмедер вакыттан соң бераз җылынган кебек булды...”* **Бу өзек кайсы әсәрдән?** (1 балл)

а) “Тапшырылмаган хатлар”
ә) “Әйтелмәгән васыять”
б) “Бәхилләшү”
в) “Мәхәббәт тәүбәсе”

**II. <u>БИРЕМНӘР:</u>**

**1. Нәрсә ул дастан? Бу жанр өчен нинди сыйфатлар хас? Дастан жанрында язылган нинди әсәрләр беләсез? Аларга хас үзенчәлекләрне әйтегез.** (10 балл)

13. **Гадел Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” әсәренең жанр үзенчәлеген билгеләгез. Әсәрдә нинди мәсьәләләр күтәрелә? Аларның бәйләнеше аша төп теманы ачыклагыз. (**10 балл)
14. **Бу шигъри юлларны кем язган? Аның авторы турында белгәннәрегезне языгыз.** (10 балл)

*“Агыла да болыт агыла*
*Туган – үскән җирләр ягына;*
*Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр*
*Нәрсә әйтер туганнарыма?!*
*Агыла да болыт агыла...”*

## Сочинение темалары:

1. Габделҗәббар Кандалый - мәхәббәт җырчысы
2. Г. Тукай иҗатының халыкчанлыгы
3. Камал - сатирик комедияләр остасы
4. Шәфигулла агай - әдәбиятыбыздагы иң калку сатирик типлардан берсе
5. Татар әдәбиятында К.Тинчурин иҗатының әһәмияте

    *5.* Г. Исхакый иҗатының татар әдәбияты һәм сәнгате тарихында тоткан урыны
    *6.* Х. Туфан иҗатында мәхәббәт лирикасы"
    *7.* Н. Фәттахның "Сызгыра торган уклар" романында ерак тарихның чагылышы

## Кулланылган әдәбият

**Төп китаплар:**


- Хәсәнов М. Ф., Әхмәдуллин А. Г, Галимуллин Ф. Г., Нуруллин И. 3. Әдәбият. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. - Казан: Мәгариф, 2006;

- Әхмәдуллин А. Г., Галимуллин Ф. Г., Галиуллин Т. Н., Ганиева Ф. Ә., Юзиев Н. Г. Әдәбият. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. - Казан: Мәгариф, 2006.

- Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ф. Җамалиева. Татар әдәбияты. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ф. Җамалиева. Татар әдәбияты. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017.


**Интернет – ресурслар:**


http://tatar.com.ru/ все для изучения татарского языка

http://kitap.net.ru/ татарская электронная библиотека

http:/www. Kitaphane.tatar.ru Национальная библиотека Республики Татарстан

http://tatar.info/ проект свободной многоязычной энциклопедии о татарской нации, её культуре, языке, истории и традициям

# I – II КУРС УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ТАТАР әдәбиятыннан БЕЛЕМНӘРЕН БӘЯЛӘҮ

## 1. УКУНЫ БӘЯЛӘҮ

Укучыларның 1 минутта уку тизлеге түбәндәгечә билгеләнә:

| Группалар | Икенче ярты еллыкта | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәреф саны | | иҗек саны | | сүз саны | |
| I курслар | 465-735 | 495-765 | 190-290 | 200-300 | 85-130 | 90-135 |
| II курслар | 475-745 | 500-775 | 200-300 | 210-320 | 90-140 | 100-145 |

Уку барышында үтәлергә тиешле фонетик, орфоэпик, пунктуацион, грамматик таләпләрнең үтәлешенә нигезләнеп, бәяләр куелырга мөмкин: (алдагы таблицаны карагыз).

Искәрмәләр. 1) укуның төп максаты — текстның дөрес укылуына һәм эчтәлеген аңлауга ирешү;

2) укуны тикшереп бәя биргәнче, укучылар, укуны бәяләү нормалары белән таныштырылып, текст белән эшләү күнекмәләре алырга тиеш.

## ЯЗМА ЭШЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ

Әдәбият буенча бирелгән белемнәрнең үзләштерелү дәрәҗәсен, язуда дөрес кулланылышын тикшерү максатыннан әдәбият дәресләрендә төрле язма эшләр –образларга характеристикалар, сочинениеләр, рецензияләр һ. б. яздырыла. Сочинениеләрне бәяләгәндә, орфографик һәм пунктуацион хаталар белән бергә, теманың ачылу дәрәҗәсе, язманың тел байлыгы (С), грамматик ялгышлары (Г.), логик (Л.) һәм фактик (Ф.) хаталар да исәпкә алына.

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>— фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>— татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) саклanса;<br>— җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр — иҗекләргә; җөмлә — сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>— тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса;<br>— интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | «5»ле билгесе куела. |
| 1. | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә ягъни:<br>— кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре | «4» ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| <br><br><br><br>2. | орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>— сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>— җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирелсә; | |
| 1.<br><br>2.<br><br>3. | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | «3»ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br><br>3.<br><br>4. | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда; | «2» ле билгесе куела. |

Язма эшләрдә җибәрелгән хаталар тупас һәм тупас булмаган хаталарга бүленеп йөртелә.

Тупас хаталарга алдагы сыйныфларда һәм бу уку елында үтелгән орфографик, грамматик һәм пунктуацион кагыйдәләргә караган хаталар керә.

Тупас булмаган орфографик хаталар:

— укучы үзе төзәткән орфографик хаталар (өч хатасын үзе төзәткән укучының эше бер баллга түбән бәяләнә); язылышы татар теле кагыйдәләренә туры килмәгән ялгышлар (Акъегет, көньяк, төньяк, Сибгат һ. б.); мәгънәләре төрлечә кулланылган кушма яки тезмә сүзләрне бутап язу (аш казаны — ашказаны, бер үк — берүк, кай вакыт — кайвакыт, ике йөзле — икейөзле, ил гизәр — Илгизәр, өй алды — өйалды һ. б.);

— программа нигезендә өйрәнү күздә тотылмаган яки соңрак үтеләчәк теоретик материалларга караган орфографик хаталар;

— беренче тапкыр очраган алынма сүзләрне, шулай ук тар профессиягә караган атамаларны язудагы хаталар;

— дәреслектә күрсәтелмәгән очракларга караган сүзне юлдан юлга күчерүдә ялгышу.

Тупас булмаган пунктуацион хаталарга җөмлә эчендәге синтагмаларны яки кушма җөмлә өлешләрен аеру өчен, функцияләре бердәй булган тыныш билгеләренең берсе урынына икенчесен кую (теркәгечләрдән башка бәйләнгән ике тиңдәш кисәкнең берсе икенчесенә каршы куюны белдергән очракта сызык яки өтер кую; гомумиләштерүче сүзләр янында — ике нокта яки сызык; аныклагычлар янына — сызык, ике нокта, җәяләр яки ике яктан өтер; ымлык яки аваз ияр-темнәреннән соң — өтер яки өндәү билгесе; теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә — өтер, нокталы өтер яки сызык; тиңдәш кисәкләр арасында — өтер яки нокталы өтер; иярчение кушма җөмләдә — өтер яки ике нокта; туры сөйләм янында — сызык, өтер яки сызык, күп нокта һәм сызык, ике нокта һәм сызык; тиңдәш түгел аергычлар арасына өтер кую; берничә тыныш билгесе бергә очрашкан урыннарда ялгышу; үзара бик тыгыз бәйләнештәге гади җөмлаләрне өтер, сызык яки ике нокта белән аерып язу; тезмә кушма җөмләләрнең өлешләрен нокта белән аерып, шул фикерне гади җөмләләр итеп бирү) керә.